ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.06.2021 ел Баулы шәһәре №102

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен
карау буенча эш тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау максатларында, Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 28 июнендәге
102 номерлы карар белән
расланган

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитетында
гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси
кабул итүне тәэмин итү буенча эш алып бару
тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгатьләрне) кабул итү, исәпкә алу, теркәү, карау, аларны карау һәм үтәүне тикшереп тору кагыйдәләрен билгели, мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклау тәртибен, шулай ук Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыруны билгели.

Әлеге Тәртип нигезләмәләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - ФЗ), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - ТРЗ) белән билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле барлык мөрәҗәгатьләргә кагыла.

1.2. Гражданнар шәхсән мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр җибәрергә (башкарма комитетка һәм вазыйфаи затларга гражданнар берләшмәләренең, шул исәптән юридик затларның, мөрәҗәгатьләрен дә кертеп) хокуклы.

1.3. Гражданнар мөрәҗәгать итүгә хокукны ирекле нигездә гамәлгә ашыралар. Гражданнарның мөрәҗәгать итүгә хокукларын гамәлгә ашыру башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозмаска тиеш.

1.4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау түләүсез нигездә тормышка ашырыла.

## 2. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп терминнар

Әлеге Тәртип максатлары өчен түбәндәге төп терминнар кулланыла:

1) гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - Баулы муниципаль районы башкарма комитетына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә юлланган тәкъдимнәр, гариза яисә шикаять, шулай ук гражданның телдән мөрәҗәгате;

2) тәкъдим - гражданның законнарны һәм башка норматив хокукый актларны, Баулы муниципаль районы башкарма комитеты эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча тәкъдимнәре;

3) гариза - гражданның аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яисә башка затларның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турындагы үтенече, яки законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозу, башкарма комитет һәм вазыйфаи затлар эшендә кимчелекләр турында хәбәре, яки күрсәтелгән орган һәм вазыйфаи затлар эшчәнлеген тәнкыйтьләү;

4) шикаять - гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен яисә законлы мәнфәгатьләрен яки башка затларның хокукларын, ирекләрен яисә законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турындагы үтенече;

5) вазыйфаи зат - хакимият вәкиле функцияләрен даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләт буенча башкаручы яки Баулы муниципаль районы башкарма комитетында дәүләт идарәсендә оештыру-күрсәтмә, административ-хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

## 3. Мөрәҗәгатьне караганда граждан хокуклары

Мөрәҗәгатьне караганда граждан түбәндәгеләргә хокуклы:

1) өстәмә документлар һәм материаллар тапшырырга йә аларны теркәү турындагы үтенеч белән, шул исәптән электрон рәвештә мөрәҗәгать итәргә;

2) башка затларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылмаса һәм күрсәтелгән документларда һәм материалларда дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр булмаса, мөрәҗәгатьне карауга кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышырга;

3) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап алырга;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә, мөрәҗәгатьне карауга бәйле рәвештә кабул ителгән карарга яисә гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белән мөрәҗәгать итәргә;

5) мөрәҗәгатьне карауны туктату турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә.

## 4. Гражданның мөрәҗәгатенә бәйле иминлек гарантияләре

1. Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затның күрсәтелгән орган яисә вазыйфаи зат эшчәнлеген тәнкыйтьләп яки үз хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яки башка затларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау максатларында мөрәҗәгать иткән гражданны эзәрлекләү тыела.

2. Мөрәҗәгатьне караганда, мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка фаш итү рөхсәт ителми. Компетенциясенә язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне фаш итү булып тормый.

## 5. Язма мөрәҗәгатькә таләпләр

1. Граждан үзенең язма мөрәҗәгатендә мәҗбүри тәртиптә язма мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органы исемен йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, йә тиешле затның вазыйфасын, шулай ук үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта), җавап җибәрелергә тиеш почта адресын күрсәтә, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында үтенеч яза, тәкъдимнәрнең, гаризаларның яисә шикаятьләрнең асылын бәян итә, шәхси имзаны һәм датаны куя.

2. Кирәк булган очракта, үзенең дәлилләрен раслау өчен, граждан язма мөрәҗәгатькә документлар һәм материалларны йә аларның күчермәләрен кушып бирә.

3. Язма мөрәҗәгать Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка кергән вакыттан алып өч көн эчендә мәҗбүри теркәлергә тиеш.

4. Башкарма комитет яки вазыйфаи затның компетенциясенә керми торган мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгатьтәге мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, гражданга мөрәҗәгатьне башка адресны җибәрү турында хәбәр юллана (әлеге Тәртипнең 7 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш).

миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу ихтималы фактлары турында мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать, мөрәҗәгатьне юллаган гражданга аның мөрәҗәгате башка адреска җибәрелү турында хәбәр итеп (әлеге Тәртипнең 17

статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш), теркәлгән көннән алып биш көн эчендә эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органына һәм Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) җибәрелә.

Язма мөрәҗәгать текстын укырлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, һәм ул дәүләт органына, МСУ органына яисә вазыйфаи затка карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса (11 статьяның 4 өлеше). Әлеге мөрәҗәгать Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карамагына тапшырыла.

5. Җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат, язмача мөрәҗәгать башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә башка вазыйфаи затка җибәрелгәндә, күрсәтелгән органнардан яисә вазыйфаи заттан язма мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре турында документлар һәм материаллар соратып алырга мөмкин.

6. Кабул ителгән карарларына шикаять бирелә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка шикаять җибәрү тыела.

7. Әгәр мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына, вазыйфаи затка, әлеге Тәртипнең 5 статьяның 6 өлешендә каралган тыю нигезендә, шикаять җибәрү мөмкин булмаса, шикаять гражданинга кайтарыла - тиешле карарга яисә гамәлгә (гамәл кылмауга) билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерү хокукын аңлатып.

## 6. Мөрәҗәгатьне карау

1. Баулы муниципаль районының Башкарма комитетына яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә кергән мөрәҗәгатьне карау мәҗбүри.

2. Кирәк булган очракта, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьне урынга чыгып карый алалар.

1. Башкарма комитет яисә вазыйфаи затлар:

1) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклап һәм үз вакытында, кирәк булганда мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында карауны тәэмин итәләр;

2) мөрәҗәгатьләрне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка вазыйфаи затлардан (судлардан, алдан тикшерү органнарыннан тыш) соратып алалар, шул исәптән электрон формада;

3) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрә;

4) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап бирә

5) гражданга аның мөрәҗәгатенең башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә башка вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә карауга җибәрелүе турында хәбәр итә.

3. Мөрәҗәгатькә җавапны дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат имзалый.

4. Мөрәҗәгатькә җавап дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча һәм дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелгән почта адресы буенча электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Моннан тыш, Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка кергән, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына карата шикаять белдерелә торган мөрәҗәгатькә җавап (шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлату) «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше таләпләрен үтәп, http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

## 7. Аерым мөрәҗәгатьләрне карау тәртибе

1. Язма мөрәҗәгатьтә гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә хокукка каршы эш әзерләнүе, кылынуы, шулай ук аны башкарган яки әзерли торган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать аның компетенциясе нигезендә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

2. Суд карарына карата шикаять белдерелә торган мөрәҗәгать, теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгать җибәргән гражданга әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып кайтарыла.

3. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары вазыйфаи затка, шулай ук аның гаилә әгъзаларына карата цензурасыз яисә мыскыллаучы сүзләр, тормышына яки сәламәтлегенә янау булган язмача мөрәҗәгать алганда, мөрәҗәгатьне анда куелган

сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм мөрәҗәгатьне юллаган гражданга хокуктан явызларча файдалану ярамавы турында хәбәр итәргә хокуклы.

4. Язма мөрәҗәгать тексты укырылык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса.

4.1. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул үз компетенцияләре нигезендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка карауга җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.

5. Гражданның язма мөрәҗәгатендәге сорауга элегрәк берничә тапкыр җавап биирелгән булса һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр китерелмәсә, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат йә ул вәкаләт бирелгән зат әлеге мәсьәлә буенча чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр бирелә.

5.1. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка килгән язмача мөрәҗәгатькә җавап, әлеге Тәртипнең 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта урнаштырылган булса, мөрәҗәгать юллаган гражданинга, мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып җиде көн эчендә, мөрәҗәгатькә куелган сорауга җавап урнаштырылган "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта ул суд карарына шикаять белдерүне үз эченә алган мөрәҗәгать кире кайтмый.

6. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавапны дәүләт яисә федераль закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча биреп булмаса, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга, күрсәтелгән белешмәләрне фаш итүнең ярамаганлыгына бәйле рәвештә, анда куелган сорауның асылына җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

7. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелмәгән сәбәпләр бетерелгән очракта, гражданин тиешле дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә тиешле вазыйфаи затка яңадан мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

### 8. Язма мөрәҗәгатьне карау сроклары

1. Дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә кергән язма мөрәҗәгать, әлеге статьяның 1.1 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, язма мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көн эчендә карала.

1.1. Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) кергән һәм миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу ихтималы фактлары турында мәгълүмат булган язма мөрәҗәгать язма мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 20 көн эчендә карала.

2. Гарызнамә юлланган очракта, Башкарма комитетның вазыйфаи затлары йә шуңа вәкаләтле зат, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр итеп, мөрәҗәгатьне карау срогын 30 көннән дә артыграк булмаган вакытка озайтырга хокуклы.

## 9 . Гражданнарны шәхсән кабул итү

1. Дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында гражданнарны шәхсән кабул итү аларның җитәкчеләре һәм шуңа вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә. Гражданнар кабул итү урыны, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турындагы мәгълүмат җиткерелә.

2. Шәхси кабул иткәндә граждан аның шәхесен таныклый торган документ күрсәтә.

3. Телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге гражданның шәхси кабул итү карточкасына кертелә. Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм билгеле булса һәм өстәмә тикшерүне таләп итмәсә, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгать итүгә шәхси кабул итү барышында телдән җавап бирелергә мөмкин, бу хакта гражданның шәхси кабул итү карточкасына язу кертелә. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

4. Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм каралырга тиеш.

5. Мөрәҗәгатьтә Башкарма комитет яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган очракта, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында аңлатма бирелә.

6. Шәхси кабул итү барышында гражданга, элегрәк бу мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирелгән булса, алга таба мөрәҗәгатьне караудан баш тартырга мөмкин.

## 10. Мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен тикшереп тору

10.1. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары үз компетенцияләре чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыралар, мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

10.2. Язма мөрәҗәгать тексты укырлык булмаса, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, һәм ул дәүләт органына, МСУ органына яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре нигезендә карауга җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгать җибәргән гражданга, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укырлык булса, хәбәр ителә (11 статьяның 4 өлеше). Күрсәтелгән мөрәҗәгать Башкарма комитет документларына теркәлә.

10.3. Язма мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатьне җибәргән гражданның фамилиясе булмаса һәм җавап җибәрелергә тиешле почта адресы язылмаса, җавап бирелми (11 статьяның 1 өлеше). Мондый мөрәҗәгать аноним дип танылa һәм тиешле эшкә теркәлә.

Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә шәхси һәм җәмгыять иминлегенә янаучы җинаятьләр һәм вакыйгалар турында мәгълүмат булса, мөрәҗәгать теркәлергә һәм тиешле компетентлы органнарга җибәрелергә тиеш.

10.4. Суд карарына карата шикаять белдерелә торган мөрәҗәгать гражданга әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибенең аңлатмасы белән (11 статьяның 2 өлеше) кайтарыла.

10.5. Әгәр кергән мөрәҗәгатьтә Башкарма комитет вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау, цензурасыз, яисә кимсетүле сүзләр булса, ул җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга мөрәҗәгать итү хокукыннан явызларча файдалануның ярамавы турында хәбәр ителә (ФЗ маддәсенең 3 өлеше). Мөрәҗәгать тиешле чаралар күрү өчен тиешле органга җибәрелә.

10.6. Гражданның язма мөрәҗәгатендәге сорауга элегрәк берничә тапкыр җавап биирелгән булса һәм шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр китерелмәсә, җитәкче, күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләр бер үк МСУ органына яисә бер үк вазыйфаи затка юлланган очракта (11 статьяның 5 өлеше), әлеге мәсьәлә буенча чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга хәбәр ителә.

10.7.Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба - җитәкче) гражданнарны атна саен сишәмбе көннәрендә 13.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр алдан язылу буенча шәхсән кабул итә.

Җитәкче урынбасарлары гражданнарны сишәмбе көнне 13.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр алдан язылу буенча кабул итә.

10.8. Кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, кабул итү урыны турында мәгълүмат, алдан язылу өчен телефон номерлары Баулы муниципаль районы сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук административ бинада мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

10.9. Башкарма комитетта гражданнарны кабул итү турында язманы һәм исәбен гомуми бүлекнең беренче категорияле белгече алып бара.

10.10. Граждан шәхси кабул иткәндә аның шәхесен таныклый торган документ күрсәтә (13 статьяның 2 өлеше). Граждан мондый документны күрсәтүдән баш тарткан очракта, аның мөрәҗәгате аноним буларак карала.

10.11. Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгатенең асылын җентекләп тикшерергә тиеш. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр билгеле булса һәм өстәмә тикшерү таләп итмәсә, гражданның ризалыгы белән мөрәҗәгатькә җавап шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу хакта гражданның шәхси кабул итү карточкасына язма кертелә.

10.12. Телдән җавапка ризалык гражданин имзасы белән раслана.

Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә. Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать әлеге Тәртип билгеләгән тәртиптә теркәлергә һәм каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә Башкарма комитет компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган очракта, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәклеге турында аңлатма бирелә.

10.13. Телдән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге гражданнарны кабул итүне теркәү карточкасына кушымта нигезендә кертелә.

10.14. Башкарма комитетның вазыйфаи затлары гражданнарны шәхси кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча МСУның башка органнарына, предприятие, оешма һәм учреждениеләргә мөрәҗәгать итәргә хокуклы, аларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре түбәндәгеләрне бурычлы:

- кирәкле белешмә һәм мәгълүмат материалларын (норматив хокукый актлар нигезендә таратылырга тиеш булмаган белешмәләрдән тыш) тапшырырга;

квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә;

- хезмәткәрләрне гражданнарны кабул итү өчен җибәрергә һ.б.

## 11. Гражданнар хатларын кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу

11.1. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә аларның адресларының дөреслеге тикшерелә. Тиешле адреска җиткерелмәгән хатлар, адресатка җибәрелү өчен кичекмәстән, элемтә предприятиесенә әйләнеп кайта.

11.2.Башкарма комитетка кәгазьдә яисә электрон почта аша кергән барлык язма мөрәҗәгатьләр керү вакытыннан алып өч көн эчендә теркәлә һәм электрон документлар әйләнеше системасына мәҗбүри элено.

11.3. Барлык мәсьәләләр дә каралган, алар буенча тиешле чаралар күрелгән һәм гамәлдәге законнарга туры килә торган тулы җаваплар бирелгән булса, гражданнарның хатлары хәл ителгән дип санала.

11.4. Башкарма комитетның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклап һәм үз вакытында, кирәк булган очракта мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында карауны тәэмин итәләр;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны башка дәүләт органнарыннан, МСУ органнарыннан һәм башка вазыйфаи затлардан соратып алалар;

в) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яисә яклауга юнәлдерелгән чаралар күрә;

г) мөрәҗәгать асылы буенча язма җаваплар бирә (Федераль законның 11 статьясындагы 1-6 өлешләрендә күрсәтелгән очраклардан тыш);

д) гражданга аның мөрәҗәгатенең МСУның башка органына яисә башка вазыйфаи затка карауга җибәрелүе турында хәбәр итәләр.

11.5. Башкарма комитетка гомуми файдаланудагы мәгълүмат системалары буенча кергән мөрәҗәгать әлеге Тәртип нигезендә каралырга тиеш.

11.6. Мөрәҗәгатьне караганда мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Шулай ук гражданның иминлек органнарында мөрәҗәгатьләрне карауга турыдан-туры катнашы булмаган затларга МСУ органнарына мөрәҗәгать итү факты һәм аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр ителергә тиеш түгел. Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне җибәрү белешмәне тарату булып тормый (ФЗ 6 статьясының 2 өлеше).

11.7. Башкарма комитетка яисә вазыйфаи затка кергән гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре, теркәлгәннән соң 30 көн эчендә, үз компетенцияләре нигезендә карала.

11.8. Башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьләрне карау срогы аларны органда теркәгән көннән башлана. Мөрәҗәгатьләрне карау срогы тәмамлану дип мөрәҗәгать авторына җавап язу датасы санала.

11.9. Билгеләнгән тәртиптә каралган мөрәҗәгатьләр буенча карарлар чикләнгән рәвештә таралган хезмәт мәгълүматына кертелә алмый.

Мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы буенча җавапны Федераль закон белән саклана торган серне тәшкил итүче мәгълүматны таратудан башка биреп булмаса, мөрәҗәгать юллаган гражданинга моның хакында хәбәр ителә (ФЗ 11 статьясының 6 өлеше).

11.10. Язма мөрәҗәгатькә җавап Башкарма комитет бланкында әзерләнә. Җавап граждан тарафыннан күрсәтелгән почта яки электрон адреска җибәрелә.

Ике һәм аннан күбрәк затның мөрәҗәгатенә (коллектив мөрәҗәгать) җавап беренче имзалаган зат исеменә (әгәр мөрәҗәгатьтә конкрет зат әйтелмәсә) җиберелә яки аерым очракларда - мондый мөрәҗәгатьне имзалаучыларның һәркайсына.

11.11. Гражданнар Башкарма комитетка һәм аларның вазыйфаи затларына Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телләрендә яисә үзләре белгән Россия Федерациясе халыкларының теләсә кайсы телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла (Татарстан Республикасы Законының II бүлеге 5 статьясы).

11.12. Башкарма комитетта гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча рәсми эшләр, хокукый актлар таләпләре нигезендә, башка рәсми эшләрдән аерым алып барыла.

## 12. Коррупция фактлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

12.1. Коррупция фактлары турында гражданнарның мөрәҗәгатьләре коррупция һәм янап куркытып (акча) алу фактлары, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу, шулай ук вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу турында белешмәләрне үз эченә ала.

12.2. Башкарма комитетка кергән коррупция фактлары турында гражданнарның мөрәҗәгатьләре әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

12.3. Мөрәҗәгатьне алдан карау процедурасын уздырганнан соң, коррупциячел хокук бозулар турында мәгълүмат ачыклангач, мөрәҗәгать кичекмәстән җитәкчегә тапшырыла. Җитәкче резолюция куя һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

12.4. Коррупция фактлары турында гражданнар мөрәҗәгатен караганда, мөрәҗәгатьләрдәге белешмәләрне, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы белешмәләрне аның ризалыгыннан башка тарату рөхсәт ителми. Карала торган мәсьәләнең барлык шартларын ачыклаганчы компетенциясенә мөрәҗәгатьтәге мәсьәләләрне хәл итү кергән вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне җибәрү мөрәҗәгатьтәге белешмәләрне тарату булып тормый.

12.5. Мөрәҗәгать карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмаулары) мөрәҗәгать итү предметы булган дәүләт органына, ҖҮИ органына яисә вазыйфаи затка җибәрелми.

12.6. Мөрәҗәгатьтә әзерләнүче, кылынган яисә кылыначак хокукка каршы эш турында, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында белешмәләр булган очракларда мөрәҗәгать теркәлә һәм тиешле дәүләт органына җибәрелә.

12.7. Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәткә бәйле бурычларын, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәмәве турында, муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы булу турында, мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү, муниципаль хезмәткәрләрнең башка коррупцион хокук бозуларны кылу ихтималы турында белешмәләр булган очракта, Җитәкче, кадрлар хезмәтенең хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе вазыйфаи затының (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның) доклад запискасы нигезендә, мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү уздыруның максатчанлыгы турында карар кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибе таләпләренең үтәлешен (муниципаль хезмәткәрләрнең «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәвен) тикшерү булып тора һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүне тикшерү турында» 2015 елның 2 февралендәге ПУ-71 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә уздырыла.

12.8. Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләү чараларын уздыру юлы белән тикшерелергә тиеш булса, мөрәҗәгатьне карау процессында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнарына запрос җибәрелә.

12.9. Күрсәтелгән тикшерүне уздырганда муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәвен таныклый торган фактлар ачыкланса, Җитәкче тикшерү материалларын Баулы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында комиссиясенә (алга таба - Комиссия) тапшыру турында карар кабул итә.

Күрсәтелгән мәсьәләне карау турында карар кабул ителгәндә Комиссия утырышында утырышның датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук Комиссия утырышын норматив хокукый актлар нигезендә әзерләү эше оештырыла.

12.10. Мөрәҗәгатьтәге мәсьәләләрнең асылы буенча җавапта уздырылган чаралар нәтиҗәләре һәм тикшерүләр турында, Комиссия карарлары (булган очракта), шулай ук кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән муниципаль хезмәткәргә җаваплылык чараларын куллану турында йә тикшерү үткәрү өчен нигезләрнең булмавы һәм коррупция фактлары расланмавы хакында мәгълүмат булырга тиеш.

12.11. Мөрәҗәгать гражданга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап җибәрелгәннән соң контрольдән алына.

_______________________